Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге Башлыгы

# КАРАРЫ

1 октябрь, 2024 ел № 2

Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Белкино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 127 номерлы (2021 елның 14 декабрендәге 34 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) Белкино авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Белкино авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Чертово авылында. 2024 елның 15 октябрендә 10.00 сәгатьтә Икмәк урамындагы 4 нче йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2025 елда Белкино авыл җирлеге Чертово торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары бер тапкыр бирелә торган түләүләрен (үзара салымын) түләүдән азат ителүе белән яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү (зиратка), ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Белкино авылында. Гражданнар җыенын 2024 елның 15 октябрендә 12.00 сәгатьтә Мәктәп урамындагы авыл мәдәният йортында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2025 елда Белкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү (зиратка), ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Белкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге башлыгы А. Н. Меньшов